Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
Арча шәһәр муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр
башкарма комитеты
422000, ТР, Арча ш., Совет мәйданы, 27
тел. 3-15-25, 3-12-35

Муниципальное образование
город Арск
Арского муниципального района Республики
Татарстан
исполнительный комитет
города Арск
422000, РТ, г.Арск, площадь Советская, 27
тел. 3-15-25, 3-12-35

# КАРАР

« 3 » март 2023 ел № 39

**"Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" Арча шәһәре башкарма комитетының 2022 елның 25 мартындагы 31 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, "Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында"2010 елның 22 июлендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып, "Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында" Башкарма комитет карары нигезендә Арча шәһәре башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. "Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2022 елның 25 мартындагы 31 номерлы Арча шәһәре башкарма комитеты карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3.2.1 пунктының 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Формалаштырылган запросны формат-логик тикшерү гариза бирүченең электрон формадагы һәр кырын тутыру процессында орган (оешма) тарафыннан билгеләнә торган таләпләр нигезендә бердәм портал тарафыннан

автомат рәвештә башкарыла. Гаризаның электрон формасының дөрес тутырылмаган кыры ачыклаганда, гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны электрон рәвештә төзәтү тәртибе турында хәбәр ителә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы сайтында (arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитетнын әйдәп баручы белгеченә йөкләргә.

Арча шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф.Касыймов